Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлегенең Нарат торак пунктында **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 ел, 12 октябрь №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Нарат торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ:**

1. I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан, иректән мәхрүм ителгәннәрдән кала, Девәтернә авыл җирлеге Нарат авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2020 елда үзара салым акчаларын 1000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- җирлектәге торак пунктлар чикләрендә төзекләндерү, тәртиптә тоту буенча эшләр башкару өчен тагылма җайланмалары белән МТЗ-82 тракторы сатып алу;
- Нарат авылы урамнарын яктырту өчен светодиодлы яктырткычлар сатып алу;
- Нарат авылындагы скважина өчен насослар сатып алу һәм ремонтлау; сууткәргеч челтәрен ремонтлау.

3. Гражданнарның җыен нәтиҗәләрен Девәтернә авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.М. ЙОСЫПОВ